# КАРАР

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Югары Шепкә авыл җирлеге составына керүче Имәнлебаш торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**16.11.2023** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2023 елның 16 нче ноябрендә булып узган гражданнар җыены нәтиҗәләре нигезендә түбәндәге сорау буенча беркетмә төзелде: . Яшәү урыны буенча Зәй муниципаль районы Югары Шепкә авыл җирлегенең Имәнлебаш торак пункты территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, көндез белем алучы студентлардан, I төркем инвалидлар, ялгыз яшәүче өлкән яштәге гражданнардан,Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан кала, 2024 елда үзара салымны 500 (биш йөз) сум күләмендә кертүгә һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотарга:
-информация такталары сатып алу һәм урнаштыру;
-Тренажерлар сатып алу һәм урнаштыру;
- юлга вак таш җәю.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 184 кеше, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 113 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен 98 җыенда катнашучы тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен 15 җыенда катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Югары Шепкә авыл җирлегенең Имәнлебаш торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип санарга.

2. . Яшәү урыны буенча Зәй муниципаль районы Югары Шепкә авыл җирлегенең Имәнлебаш торак пункты территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, көндез белем алучы студентлардан, I төркем инвалидлар, ялгыз яшәүче өлкән яштәге гражданнардан,Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан кала, 2024 елда үзара салымны

500 (биш йөз) сум күләмендә кертүгә һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотарга:
- информация такталары сатып алу һәм урнаштыру;
-Тренажерлар сатып алу һәм урнаштыру;
- юлга вак таш җәю буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3.Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Югары Шепкә авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән гражданнар җыены нәтиҗәләрен игълан итәргә, Зәй муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» урнаштырырга (PRAVO.TATARSTAN.RU) 7 көн дәвамында кабул ителгән көннән.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Югары Шепкә авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Югары Шепкә авыл җирлеге башлыгы Камалиева Л.М.